КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 май г.Казань № 333

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 885 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 885 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 гыйнвар, 13 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда:

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.4. | «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе | юл эшчәнлеген гамәлгә ашырганда гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларын үткәрү | 750 395 500,0 |
| | | гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында үлчәү тикшерүен гамәлгә ашырганда авыр йөкләр ташый торган транспорт чараларын үлчәү | 215 937 000,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне инновацион, эшмәкәрлек, ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең гражданлык активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чараларны оештыру | 30 467 200,0 |
| | | транспорт чараларын күчерүне һәм саклауны оештыру, шулай ук махсуслаштырылган транспорт куеп тору урыннарын эксплуатацияләү (тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган транспорт куеп тору урыннарына күчерү) | 98 804 325,6 |
| | | транспорт чараларын күчерүне һәм саклауны оештыру, шулай ук махсуслаштырылган транспорт куеп тору урыннарын эксплуатацияләү (махсуслаштырылган транспорт куеп тору урыннарында тоткарланган транспорт чараларын саклау һәм исәпкә алу) | 102 017 474,4 |
| | | оешма эшчәнлеген администраив тәэмин итү (анализ үткәрү) | 38 982 786,1 |
| | | оешма эшчәнлеген администраив тәэмин итү (экспертиза үткәрү) | 38 982 786,1 |
| | | оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү (анализ үткәрү) | 11 332 205,3 |
| | | мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасының мәгълүмат системаларын һәм компонентларын булдыру һәм үстерү | 80 809 774,8 |
| | | гамәли фәнни тикшеренүләр үткәрү | 14 051 934,5 |
| | | мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасы компонентларын техник тәэмин итү һәм эксплуатацияләү, эксплуатацияләүдән чыгару | 80 232 013,2»; |

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3.3. | «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | кадастр кыйммәтен билгеләү өчен кирәкле (шул исәптән күчемсез мөлкәт базары белешмәләре турында) мәгълүматны, шулай ук дәүләт кадастр бәяләвен үткәргәндә файдаланылган һәм аны үткәрү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган мәгълүматны җыю, эшкәртү, системага салу һәм туплау | 2 839 303,88 |
| | | яңа исәпкә алынган күчемсез мөлкәт объектларының, элек исәпкә алынган күчемсез мөлкәт объектларының (алар турындагы мәгълүматлар Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертелән очракта) һәм микъдары һәм (яки) сыйфаты ягыннан тасвирнамәләренә үзгәрешләр булганда күчемсез мөлкәт объектларының кадастр кыйммәтен билгеләү | 2 654 079,9 |
| | | дәүләт кадастр кыйммәтен үткәргәндә күчемсез мөлкәт объектларының кадастр кыйммәтен билгеләү | 2 282 699,17 |
| | | кадастр кыйммәтен билгеләгәндә файдаланылган документлар һәм материаллар күчермәләрен саклау | 1 657 306,83 |
| | | хисапларны һәм кадастр кыйммәтен билгеләү барышында формалаштырыла торган башка документларны саклау | 1 771 799,11 |
| | | Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, саклана торган хисаплар һәм кадастр кыйммәтен билгеләү барышында формалаштырылган документлар, шулай ук кадастр кыйммәтен билгеләгәндә кулланылган документлар һәм материаллар күчермәләрен хокук саклау, суд һәм | 1 466 486,36 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | башка вәкаләтле дәүләт органнарына аларның таләбе буенча бирү | |
| | | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен кирәкле мәгълүматны дәүләт кадастр исәбен һәм бюджет учреждениесе карамагында булган хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына бирү | 1 542 814,54»; |

әлеге карар белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда һәм аларның күләмнәрендә:

1.2 пунктның 4 графасында «111,88» саннарын «114,98» саннарына алмаштырырга;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «2.1. | «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | кадастр кыйммәтен билгеләүгә бәйле аңлатмалар бирү | 117 165,06 | 20,0 | аңлатмалар бирелгән күчемсез мөлкәт объектлары саны, берәмлек |
| | | кадастр кыйммәтен билгеләгәндә җибәрелгән хаталарны төзәтү турындагы гаризаларны карау | 113 350,45 | 20,0 | кадастр кыйммәтен билгеләгәндә җибәрелгән хаталарны төзәтү турындагы гаризалары каралган күчемсез мөлкәт объектлары саны, берәмлек»; |

түбәндәге эчтәлекле 4 бүлек өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «4. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы учреждениеләре | | | | |
| 4.1. | «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү буенча компетенцияләр үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе | кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына консультация һәм мәгълүмат ярдәме күрсәтү | 21 786,49 | 170,0 | хезмәт күрсәтүдән файдалану өчен мөрәҗәгать иткән кече эшмәкәрлек субъектлары саны, берәмлек». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин